ГЛАВА
ВВЕДЕНСКО-СЛОБОДСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ВВЕДЕНСКИЙ БИСТӘСЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

26.10.2021 с. Введенская Слобода №4

Югары Ослан муниципаль районы Введенский Бистәсе авыл җирлегенең
Савино авылында гражданнарның үзара салым акчаларын
кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56нчы ст., «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35нче ст., Югары Ослан муниципаль районының Введенский Бистәсе авыл җирлеге Уставының 24нче статьясына туры китереп,

КАРАР БИРӘМ:

1. 2021 нче елның 13 нче ноябренә Югары Ослан муниципаль районы Введенский Бистәсе авыл җирлегенең Савино авылында гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Югары Ослан муниципаль районы Введенский Бистәсе авыл җирлегенең Савино авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2022 нче елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?:

Савино авылында җирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерү

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Савино авылы, Дорожная урамы, 10 нчы йорт адресы буенча урнашкан йорт яны территориясендә гражданнар җыены үткәрергә.

4. Введенский Бистәсе авыл җирлеге Башкарма комитетын халык җыенын оештыручы итеп билгеләргә.

5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Югары Ослан муниципаль районы
Введенский Бистәсе авыл җирлеге
башлыгы Д.В. Морозов